**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Манзарас авыл җирлеге**
**муниципаль берәмлеге**

# КАРАР

**2022 елның 27 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 27 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Манзарас авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), бишенче линияне төзү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Манзарас авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Манзарас авылына янгын гидрантлары һәм комплектлау җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, янгын гидрантларын комплектлау, смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Манзарас авылы территориясен төзекләндерү;
- Манзарас авылы юлларына асфальт җәю, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, экспертиза үткәрү;
- Манзарас авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Яңгыр канауларын һәм канализацияләрен урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын уздыруны оештыру: булган яссылык спорт корылмаларын карап тоту, тренировкалар оештыру, спорт чараларын әзерләү һәм уздыру өчен белгеч тоту;

- Манзарас авылына янгын гидрантлары һәм комплектлау җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Парковка урыннарын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылында тротуарлар төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылы Мәдәният йортын карап тоту, Мәдәният йорты котельнаясын ремонтлау, Мәдәният йорты залы өчен кәнәфиләр сатып алу .

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 1007 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 533.

Тавыш биру нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 526 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 7 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Манзарас авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Манзарас авылында урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), бишенче линияне төзү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Манзарас авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылына янгын гидрантлары һәм комплектлау җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, янгын гидрантларын

комплектлау, смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылы территориясен төзекләндерү;

- Манзарас авылы юлларына асфальт җәю, торбалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру, экспертиза үткәрү;

- Манзарас авылында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау (торбаларны алыштыру, материал, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Яңгыр канауларын һәм канализацияләрен урнаштыру һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Физкультура һәм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын уздыруны оештыру: булган яссылык спорт корылмаларын карап тоту, тренировкалар оештыру, спорт чараларын әзерләү һәм уздыру өчен белгеч тоту;

- Манзарас авылына янгын гидрантлары һәм комплектлау җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, янгын гидрантларын ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Парковка урыннарын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылында тротуарлар төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Манзарас авылы Мәдәният йортын карап тоту, Мәдәният йорты котельнаясын ремонтлау, Мәдәният йорты залы өчен кәнәфиләр сатып алу .

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хәбибуллина